Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

16.09.2024 ел № 211

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен арендага бирү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советының 2016 елның 30 сентябрендәге 57 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Хуҗалык карамагындагы хокукта беркетелгән дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә карата аренда шартнамәләренең конкурсларын яки аукционнарын уздырмыйча гына, дәүләтнең яисә муниципаль мәдәният оешмаларына оператив идарә итү хокукында беркетелгән бәяләмәсен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 9 сентябрендәге 1529 номерлы карарының 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен арендага бирү тәртибе турында» 2016 елның 30 сентябрендәге 57 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 1.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 нче абзац өстәргә:

«- муниципаль мөлкәткә карата мәдәният оешмаларына арендага тапшырыла торган муниципаль мөлкәт милекчесе һәм аны гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган белән районның җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларында каралган очракларда һәм тәртиптә килештерелергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Советы рәисе Н.А. Вазыйхов